ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2016 Казан ш. № 10-22/кс

2017 – 2021 елларга каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында

“Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында” 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында” 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы карарына, “Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифларны һәм өстәлмәләрне исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” 2011 елның 15 февралендәге 47 санлы Россия Федерациясенең региональ үсеш министрлыгы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны, календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 нче кушымтасындагыча билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2017 елның 1 апреленнән 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү өлкәсендә әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән тарифларның гамәлдә булу чорына җитештерү программаларының төп күрсәткечләрен әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп килештерергә.
4. Комуналь комплекс оешмаларына билгеләнгән вакытка, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 1140 санлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

5. Әлеге карарда билгеләнгән каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының “Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыру турында” 2016 елның 12 февралендәге 35 санлы боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийларына туры килә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
30.11.2016 № 10-22/кс
карарына кушымта 1

2017 – 2021 елларга комуналь комплекс ошемалары тарафыннан билгеле бер календарь чорларына бүлеп каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы атамасы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар сум/куб.м | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | |
| | | 1 апрелдән | 1 июлдән | 1 гыйнвардан | 1 июлдән | 1 гыйнвардан | 1 июлдән | 1 гыйнвардан | 1 июлдән | 1 гыйнвардан | 1 июлдән |
| | Актаныш муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 1 | “Актанышский полигон ТБО”* муниципаль унитар предприятие | 115,75 | 115,75 | 109,63 | 109,63 | 107,68 | 107,68 | 104,95 | 104,95 | 101,65 | 101,65 |
| | Аксубай муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 2 | “Төзекләндерү”* җаваплыгы чикләнгән җәмгыять | 115,91 | 119,39 | 119,39 | 124,51 | 124,51 | 128,31 | 128,31 | 133,79 | 133,79 | 137,98 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
30.11.2016 № 10-22/кс
карарына кушымта 2

## Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә коммуналь комплекс оешмаларының җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы атамасы | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | “Актанышский полигон ТБО” муниципаль унитар предприятие | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү күләме, мең куб.м шул исәптән: | Барлыгы | 31,20 | 32,84 | 35,27 | 37,40 | 39,95 |
| | | | Халык | 21,87 | 23,52 | 25,94 | 28,08 | 30,63 |
| | | | Бюджет кулланучылары | 3,25 | 3,25 | 3,25 | 3,25 | 3,25 |
| | | | Башка кулланучылар | 6,07 | 6,07 | 6,07 | 6,07 | 6,07 |
| | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДСтан тыш) | | 3 870,29 | 4 018,64 | 4 242,91 | 4 414,51 | 4 564,79 |
| 2 | “Төзекләндерү” җаваплыгы чикләнгән җәмгыять | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү күләме, мең куб.м шул исәптән: | Барлыгы | 11,08 | 11,08 | 11,08 | 11,08 | 11,08 |
| | | | Халык | 2,86 | 2,86 | 2,86 | 2,86 | 2,86 |
| | | | Бюджет кулланучылары | 4,284 | 4,284 | 4,284 | 4,284 | 4,284 |
| | | | Башка кулланучылар | 3,94 | 3,94 | 3,94 | 3,94 | 3,94 |
| | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДСтан тыш) | | 1 321,60 | 1 369,69 | 1 419,58 | 1 471,51 | 1 525,56 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге